وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلا تَفَرَّقُواْ

Ий мөәминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

Дин вә Мәгыйшәт

№25 (168). 21 декабрь 2012 / 8-сәфәр-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

ИДЕЛ БУЕ, УРАЛ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ һәм ТАТАР ӘШМӘКӘРЛӘРЕ ▷2◁

"ТАЯН АЛЛАГА" КОНКУРСЫНА ЙОМГАК ЯСАЛДЫ ▷3◁

ӘНИЕМНЕҢ ДӘ НАМАЗ УКУЫН ТЕЛИМ... ▷4◁

Бер кешене үтерү кешелекне үтерүгә тиңләнә

Күптән түгел булып узган фажигале вакыйгалар әле сабыйлыктан да чыгып җитмәгән, утлы коралның ни икәнен белмәүче бер риясыз нарасыйларга мылтык терәрлек башкисәрләр каян барлыкка килеп тора соң ул дигән сораулар тудыра. Американың Коннектикут штатының Ньютаун шәһәрендәге канлы вакыйга нәтиҗәсендә Аллаһы Тәгаләнең иң гөнаһсыз җан ияләре - балалар корбан булды. Җинаятьче - 20 яшьлек җанкыяр, башлангыч мәктәпкә үтеп кереп, җиде яше дә тулмаган балаларга, укытучыларга пистолеттан ут ачкан. Бер-беренә терәлеп үк торган ике сыйныфтагы биш яшьтән алып җиде яшькәчә 20 баланың һәм 6 укытучының гомерен өзде ул. Бу яңалыкны укып, егетнең җанында шайтан өстенлек итүен аңлыйбыз, чөнки бу гамәлне башка берничек тә аңлатып булмый.

Барыбызда да сорау туа: гуманлылык кануннары игълан ителгән җәмгыятьтә ни сәбәпле мондый җинаятьләр килеп чыга? Моңа җавап бирү өчен безгә бер генә көнебезне булса да телевизион каналларны карауга багышларга кирәк. Күбрәк кеше игътибарын җәлеп итү максатыннан анда бөтен булган һәм булмаган әшәкелекне, вәхшилекне, дөньядагы барлык куркыныч вакыйгаларны күрсәтәләр. Кеше вәхшилекне күргән һәм ишетергә шулкадәр ияләшә ки, тереләтә яндырылып үтерелгән кешеләр өчен дә, маньяк җәзалап үтергән балалар өчен дә кайгырмый башлый. Болар барысы да кеше өчен эшкә бару,

чәй эчү кебек гадәтилеккә әйләнә. Бу Америка егете мисалында кеше гомере берни дә тормавы, аның ниндидер психологик проблемалары булуы да бар. Ләкин аларны нәрсә барлыкка китергән соң? Дөньяда булган бөтен нәрсәгә дә битараф караучы җәмгыять "гаепле" түгелме икән?!

Мөселман кешесе үз халәтен һәрвакыт күзәтеп торырга, аңа күргән һәм ишеткәннәре ни дәрәҗәдә тәэсир итүгә игътибар итәргә тиеш. Әгәр дә Коръәни-Кәримдә: "Кем дә кем кеше җанын кыймаганны үтерсә яки дөньяда бозыклык кылмаганны үтерсә, бөтен кешеләрне дә үтергән кебек булыр" ("Маидә (Табын)" сүрәсенең 32 нче аяте), - диелгән икән, димәк без дә кешенең үтерелүенә шул дәрәҗәдә кайгырырга тиешбез. Әгәр дә кайгырмыйбыз икән, күңелләребез каткан. Ә нәрсә эшләргә кирәк соң?

Телевидение программасын без куркыныч вакыйгалар белән генә түгел, ә кешелекнең төрле өлкәләрдә ирешкән уңышлары белән кызыксына башласак кына үзгәртә алабыз. Тирә-ягыбызда да, дөньяда да бик күп ачышлар ясала, искиткеч вакыйгалар һәм могҗизалар булып тора. Балаларны ил, дөнья тарихы өчен кирәкле шәхесләр буларак тәрбияләргә кирәк, аларга гомерләре - Аллаһы Тәгалә бүләге, шуңа күрә һәрберебез бу дөньяны яхшыртыр өчен үз өлешен кертергә тиеш дигән фикерне җиткерү мәслихәт. Аллаһы Тәгалә безгә гомерне начарлык таратыр өчен бирмәгән. Әгәр дә без моны онытмасак, җаннарыбызны начарлыктан саклап кала алачакбыз. Әлбәттә, бу җәмгыятьтә булган проблемалардан качарга, аларны чишү юнәлешендә эшләмәскә кирәк дигән сүз түгел. Колакларыгызны томаларга һәм күзләрегезне йомарга да өндәмим. Башкаларның кайгысына, бәхетсезлегенә битараф булмыйык, шул ук вакытта тиешсез, психикага зыян китерә торган мәгълүматны фильтр аша үткәрергә өйрәник.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) болай дигән: "... Шуңа күрә дә файда китерүгә (һәм көчегезне ныгытуга) омтылыгыз, уйламыйча эш итүгә бармагыз һәм көрәштә өметсезлеккә бирелмәгез" (Мөслим).

Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ

Аллаһ үзенең яраткан колын сынауга тартыр

Әлхәмдүлилләәһи раббил галәмииин. Вәссалләәтү вәссәләәмү галәә расүүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһи әҗмәгыйн. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим.

Аллаһтан килгән сынаулар - ул бер яктан кешенең сабырлыгын сынау булса, икенче яктан Аллаһның үз колына булган яратуының чагылышы да булып тора. Моны авыру кешегә биргән ачы дару белән чагыштырга мөмкин.

Шушы даруны эчеп авыру терелә һәм даруның ачылыгы бик тиз онытыла. Сынаулар аша үткәреп, Аллаһ кешене гөнаһлардан чистарта. Хәдистә әйтелә: "Иң югары бүләк зур сынаулар аша килә". Аллаһ яраткан бәндәсен сынауларга дучар итә. Кем тиешенчә кабул итсә, ул сөекле, әгәр канәгать булмаса, Аллаһның ачуына лаеклы булыр. Сәхабәләрнең берсе әйткән: "Әгәр сынаулар булмаса, Кыямәт көнендә без Аллаһ каршына буш кул белән килгән булыр идек". Сынаулар иманлы бәндә өчен - ул, бәлки, ахирәт тормышына кадәр ирешә торган нигъмәттер. Башкача була да алмый, чөнки аның яхшы гамәлләре гөнаһларын юа һәм Аллаһ алдында аны югары дәрәҗәгә күтәрә. Пәйгамбәребез (сгв) әйткән: "Аллаһ колын яратса, аңа авырлыклар бирер, әгәр ачуланса, аны ахирәттә җәзага тартыр". Хәсән әл-Басри: "Бәла буларак килгән сынауларга авырыксынмагыз, бәлки сез яратмаган нәрсәдә сезнең котылуыгыз бардыр, әмма сез яраткан нәрсәдә сезнең үлемегез булырга мөмкиндер", - дигән. Әл-Фадл ибн Сахл язган: "Аллаһның рәхмәте булып килгән сынауларга, акыллы кеше битараф калырга тиеш түгел, чөнки алар аның гөнаһын юа һәм түземлек, сабырлык өчен Аллаһның бүләгенә лаек була. Сынаулар кешедә киң күңеллелек тәрбияли, алар аша үтеп кеше һәрвакыт тәүбәгә һәм яхшылык эшләүгә әзер буладыр". Шулай итеп, сынаулар - кеше өчен Аллаһның рәхмәтенә ирешү юлы. Әмма моңа түземнәр, чыдамнар, сабырлар һәм ныклы иманлы кешеләр генә ирешә аладыр.

Шушы урында Пәйгамбәребезнең (сгв) хәдисен искә алу урынлы булыр, ул әйткән: "Мөселманның хәле гаҗәптер, аның белән булган бөтен хәлләр аның өчен нигъмәттер, бу иманлы кешедән башкага бирелмәгәндер, әгәр аңа сөенеч килсә, ул Аллаһка шөкер итә дә, саваплы буладыр, әгәр бәла килсә, ул сабыр итә дә, тагын саваплы буладыр".

(Ахыры 3 нче биттә.)

ЯҢАЛЫКЛАР

ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ НОРЛАТ БАЛАЛАР ЙОРТЫНДА БУЛЫП КАЙТТЫ

14 декабрь көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге Казан мөхтәсибәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге вәкилләре һәм Ризван мәчете имам-хатыйбы Алан хәзрәт Панарин белән берлектә Яшел үзән районында урнашкан Норлат балалар йортында булды. Сабыйгаларга бүләкләр, спорт кирәк-яраклары бүләк ителде һәм балалар йортына су җылыту җайланмасы тапшырылды.

Исегезгә төшерәбез: Норлаттагы ятим балалар йорты белән мөфтият бер елдан артык хезмәттәшлек итеп килә. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия бүлеге җитәкчесе Гөлнара Садыйкова сүзләренә караганда, Яңа елга кадәр сабыйларны Казанга - картингта йөрергә алып килү планлаштырыла.

ГАБДУЛЛА ХӘЗРӘТ ӘДҺӘМОВ КЫРГЫЗСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ КОРЫЛТАЕНДА КАТНАШТЫ

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов Кыргызстан Республикасы мөселманнары корылтаенда катнашты. Габдулла хәзрәт корылтайда катнашучыларны Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз исеменнән сәламләде. Ул үз чыгышында Татарстан һәм Кыргызстан мөселманнарының берлеге төрки халыкларның тарихы, теле, дине, мәзһәбе уртак булуга нигезләнгәнлекне җиткереп, мөфтиятләр арасында дуслыкны һәм үзара мөнәсәбәтләрне ныгытуның мөһимлеген ассызыклады.

Корылтайда Кыргызстан Диния нәзарәтенең яңа Уставы кабул ителде, Голамәләр шурасы әгъзалары билгеләнде. Яңа мөфти итеп Рәхмәтулла хәзрәт Әгәмбәрдиев сайланды.

"МӨХӘММӘДИЯ" МӘДРӘСӘСЕНЕҢ 130 ЕЛЛЫГЫ БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛДЕ

17 декабрь көнне Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында зур тарихка ия булган "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе үзенең 130 еллыгын билгеләп үтте.

Мәгърифәтче Галимҗан Баруди тарафыннан нигез салынган мәдрәсә шәкертләр арасында XXI гасырда да популяр. Анда ел саен көндезге, кичке һәм читтән торып уку бүлекләренә йөзләрчә студент кабул ителә.

Үз вакытында әлеге уку йортын Хөсаен Ямашев, Камил Якуб, Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури, Фәтхи Борнаш, Кәрим Тинчурин, Нәкый Исәнбәт, Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев, Бакый Урманче кебек мәшһүр затлар, татар милләтенең зыялылары тәмамлаган.

Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды

ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙЙК!

1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.

ИДЕЛ БУЕ, УРАЛ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ һәм ТАТАР ЭШМӘКӘРЛӘРЕ

(XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы)

Татар сәүдәгәрләре һәм промышленниклары, революциягә кадәрге Россиядә татар халкының күпчелеге кебек, ислам дине кануннары белән яшәүче дини кешеләр була. Аларның мөселман диненә ихлас бирелгәнлеге төрле гамәлләрендә һәм тормыш рәвешләрендә чагылыш таба. Эшмәкәрләрнең өлкән буын вәкилләре мөселманлыкның барлык таләпләрен катгый төстә үтәп яшәргә тырыша. Өлкән буын һәм урта буын вәкилләренең бар өлеше дә мәчетләргә һәм гыйбадәт кылу урыннарына даими йөри. Ә инде яшь сәүдәгәрләр һәм фабрикантлар, ислам традицияләре һәм дин кушуы буенча, асылда бәйрәм көннәрендә һәм һәр җомгада мәчетләргә күмәк намазга җыела.

Бай Казан сәүдәгәре гаиләсе. XIX-XX йөз башы.

Ата-бабалары каберләренә, аларның истәлегенә сакчыл мөнәсәбәт барлык буын эшмәкәрләренә хас була. Төбәгебездә аларның якыннары һәм туган-тумачаларының мөселман гореф-гадәтләре буенча бик әйбәт каралган каберләре шул хакта сөйли. Зәвык белән эшләнгән кабер ташлары да татар-мөселман традицияләрен ачык чагылдыра. Татар эшмәкәрләренә аларны иң шәп осталар эшләп бирә.

Тарихыбызда әдәбиятта гына түгел, татар-мөселман тормышының кайбер өлкәләрендә дә суфичылык йогынтысы билгеле бер урын алып тора. Акчуриннар үзләренең ата-бабалары каберләреннән тыш, мөселманнарның изге каберлекләре дип саналган урыннарны да күңел җылысы биреп карый. Шулар арасыннан ике каберне телгә алып үтәсе килә. Берсе - гаять хәтерле булып, бөтен Коръәнне яттан белгән, тик бик яшьли якты дөньядан киткән Пакизә исемле кызныкы (Сембер губернасындагы Карсун өязенә караган Гурьевка авылында). Икенчесе - Сембер губернасындагы Сенгилей өязенә караган Калны (Калда) авылыннан 4-5 чакрым ераклыкта урнашкан билгесез юлчы - Шаһбан бабай кабере. Әстерхан сәүдәгәрләре Габделяшит һәм Хөсәен Еремеевлар Фәрит ахун белән 1891 елның җәендә җирле мөселман каберләрен таш койма белән әйләндереп алу өчен акча җыю эшен оештыра.

Бигрәк тә атаклы сәүдәгәр Заһидулла Шәфигуллин үзенең авылдашлары (Казан губернасындагы Чуел (Цивильск) өязенә караган Акъегет авылы) каберләренә үтә сакчыл һәм ихтирамлы мөнәсәбәте белән аерылып тора. Жандармерия сводкаларында җирле зират турында "... Шәфигуллин тарафыннан бик әйбәтләп каралган" дигән сүзләр табарга була хәтта. Татар сәүдәгәрләре мөселман зиратын карап тоту өчен Ирбит ярминкәсендә даими рәвештә акча җыя.

Татар эшмәкәрләре Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрен оештыру һәм үткәрүдә дә актив катнаша. Алар бәйрәм чыгымнарын үз өстенә ала, милекләренең бер өлешен, акчаларын сәдака итеп бирә. Аксакаллар әйтүенчә, фабрикантларның кушуы буенча, бәйрәмгә килүчеләргә намаз укырга уңайлы булсын өчен мәчетләр тирәсенә киез җәелә.

Төбәкнең татар сәүдәгәрләре һәм промышленниклары, ислам таләпләрен үтәү йөзеннән, җирле мөселманнарның Мәккә һәм Мәдинәгә хаҗга баруларын оештыра. Мөселман өммәтендәге байтак кешеләр Хөсәеновлар, Рәмиевләр, Акчуриннар, Яушевлар, Дебердиевлар, Юнысовлар, Апанаевлар акчасына хаҗ кылуга ирешә.

Күп кенә татар эшмәкәрләре үзләре дә хаҗ кыла. Акчуриннар арасыннан иң беренче булып Зөя башы (Старое Тимошкино) фабрикасы хуҗасы Сөләйман Абдулла улы хаҗ кылган булса кирәк. 1864 елның маенда була бу. Фабрикантка иптәшкә фабрика мулласы Зыятдин Мөстәкыймов иярә. Сөләйманның Ильяс исемле абыйсы Акчуриннар арасыннан икенче булып Мәккә һәм Мәдинә тарафларына барып кайта. XIX гасырның 80 нче еллары урталарында Әсфәндияр Курамша улы хаҗ кыла. 1899 елда исә Тимербулат Курамша улы Акчурин Айшә исемле кызы белән бергәләп мөселманнарның изге урыннарында булып кайта. Фабрикант Дебердиевлар нәселеннән булган Мөхәммәд-Йосыф Мөхәммәд-Әмин улы да алар белән бергә хаҗ кыла. Т.К. Акчуриннның башка кызлары да хаҗияләргә әйләнә.

Изге урыннарга хаҗ кылулар җәһәтеннән Саратов фабрикантлары - Дебердиевларны аерым билгеләп үтәргә кирәк. Алар Россиядән килүчеләрне, иң элек татарларны кабул итү өчен Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә йортлар тота. Атаклы татар галиме (тарихчы, дин белгече), җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәд Морат Рәмзи мөселманнарның изге урыннарында Дебердиевларның вәкиле була. Казанның таныльган йортлар хуҗасы Мөхәммәд-Шакир Закир улы Бигаев 1917 елга кадәр Мәдинәдә, шулай ук Константинопольдә (хәзерге Истанбул. - ред.) йортлар тота. XIX гасыр урталарында Казанның атаклы сәүдәгәре Корбангали бине Мортада бине Исмәгыйль бине Йосыф бине Борнай Мәдинәдә зур тәккәләр (тәккыяләр) төзүгә акча бүлеп бирә. Татар сәүдәгәрләре һәм промышленниклары ничек тә дин эшлеклеләренә хаҗ кылу мөмкинлеге тудырырга тырыша. Ш.Мәрҗани 1880 елның 11 августында Мәккә һәм Мәдинәгә хаҗ кылырга барганда, Түбән Новгород ярминкәсенә кереп чыга. Биредә мөселман сәүдәгәрләре аңа бүләк йөзеннән 300 сум акча бирә.

Төбәк губерналарында, шулай ук аннан читтә йөзләрчә мәчет татар эшмәкәрләре акчасына төзелә һәм карап тотыла. 1853 елда Сембер сәүдәгәре Курамша Абдулла улы Акчурин губерна үзәгендә мөселманнар өчен таштан гыйбадәт кылу йорты төзи. Йорт Лосевая урамында (хәзерге Ульяновск шәһәрендәге Федерация урамы) калкып чыга. Әйтергә кирәк, инде 1838 елда ук түбән хәрби чиннар өчен шәһәр мөселманнары арасыннан мулла билгеләнеп куела. Казнадан ул елына 100 сум күләмендә акча ала. 1853 елга кадәр Сембер мөселманнары (беренче чиратта - татарлар) сәүдәгәр Ильясовның шәхси йортында намазлар укый. Курамшаның эшен Идел буе төбәгендә иң зур сукно (постау) җитештерү эшен оештырган улы Тимербулат дәвам иттерә. 1865 елда аның акчасына бик матур манара төзеп куелгач, гыйбадәт кылу йорты мәчеткә әйләнә. Сембер губернасының беренче һәм бердәнбер таш мәчете була ул. Губернаның калган 138 мәчете барысы да агачтан эшләнә. Шулай итеп, татар егетләре - сукно фабрикантлары тырышлыклары белән Сембер шәһәрендә беренче мөселман мәчете пәйда була.

XIX гасырның 70 нче еллары башында, шәһәрдә яшәүче татарлар саны сизелерлек арткач, мәчет бинасы тараеп калгандай була. Т.К. Акчурин үз диндәшләренә янә ярдәмгә килә: 1874 елда шушы изге максатка акча бүлеп бирә. Яшь сәүдәгәр һәм фабрикант биргән акча бинаны киңәйтүгә тотыла. Реконструкция ясау нәтиҗәсендә мәчет эче ян-ягыннан өч сажинга зурая. Шулай итеп, изге йорт өч йөздән артыграк кешене сыйдыра башлый. Мәчет губерна үзәгенең әллә кайдан ук күзгә ташланып торган бик матур бинасына әйләнә. Бу елларда мәчетләрне һәм алар каршында уку йортларын Сембер, Саратов губерналарында, Самарада - Акчуриннар; Оренбург губернасында (шул исәптән Чиләбедә һәм Троицкида) - Яушевлар; Самара, Оренбург, Уфа, Казан губерналарында, Идел буе һәм Урал төбәгенең башка губерналарында Хөсәеновлар сала.

Эшмәкәрләр, мәчет төзү белән беррәттән, аларны карап тотуда, файдалану, төзекләндерү, яктылык, җылылык белән тәэмин итүдә дә зур ярдәм күрсәтеп килә. XX гасыр башларында таныльган сәүдәгәр Заһидулла Шәфигуллин Казан губернасындагы Чуел (Цивильск) өязенә караган Акъегет авылындагы мәчет комплексы өчен йөзләрчә сажин утын бүлеп бирә. Авылның мөселманнар мәхәлләсе ярты гасыр дәвамында диярлек әлегә атаклы сәүдәгәр "канаты астында" яши. Шул ук вакытта З.Шәфигуллин үзенең төп сәүдә эшчәнлеген Себердә (Иркутскида), ягъни үз авылыннан шактый ерак тарафларда алып бара. Ярдәмчеллек, хәерхаһлык З.Шәфигуллинга гына түгел, төбәктәге күп кенә башка татар эшмәкәрләренә дә хас була.

XIX гасырның 80 нче елларында Саратов губернасының Кузнецк һәм Хвалын өязләрендә 124 мәчетне карап тоту халык җилкәсенә 90 мең сумга төшә. Әлегә чыгымнарның байтак өлешен татар эшмәкәрләре күтәрә.

Гыйбадәтханәләрнең күпчелендә мәгърифәтле, әзерлекле имамнар хезмәт итә. XIX гасырның икенче яртысында Сембер шәһәре мөселманнары мәчетендә Габделвәли Гаффаров указлы мулла була. 60 нчы елларда (XIX йөз) ул Сембер статистика комитетының хакыйкый әгъзасы булып тора. Акчуриннар һәм Сембер шәһәре мөселманнары арасыннан башка эшмәкәрләр төзегән күп кенә юридик документлар нәкъ менә шуның аша уза. Ул, аерым алганда, Акчуриннар һәм башка сәүдәгәр нәселенең кайбер вәкилләренә караган васыятьнамәләрне рус теленә тәрҗемә итеп калдыра.

Шулай ук XIX гасырның 70-80 нче елларында Сембер губернасының Карсун өязенә караган Ляховка авылындагы Акчуриннар фабрикасында мулла була. Ул үзенең хезмәтен иҗтимагый эш сыйфатында алып баргандыр, күрәсең. Әлегә рус авылында күпмедер эшче татарлар да яши. Асылда алар губернаның Карсун, Сенгилей өязләре һәм башка өязләрнең татар авыллары крестьяннары була. Ляховкада татар (мөселман) зираты да барлыкка килә.

XX гасыр башларында (1909 ел) Т.Акчурин ширкәтенең Самайкин фабрикасында Мөгштедин Мамышев мулла була. XIX гасыр азагы - XX гасыр башларында Самара губернасының Мулловка авылында Алиевлар фабрикасы каршындагы мәчеттә Камалетдин Раимов дигән кеше мулла хезмәтен башкара. Ул бик белемле шәхес була. Нәкъ менә шушы мулла XIX гасырның 90 нчы елларында Европа һәм Азиянең үсемлекләр, хайваннар дөньясы сүзлеген берничә телдә (гарәп, фарсы, төрек, татар, рус, француз телләрендә һәм латинча) әзерли.

Идел буе һәм Урал төбәгенең мөселманнар җәмгыятьләре Санкт-Петербургта, Мәскәүдә һәм башка сәнәгать үзәкләрендә сәүдә эшчәнлеге алып баручы якташларының даими ярдәмен тоеп яши. Татар эшмәкәрләре Санкт-Петербургта җәмигъ мәчете һәм Түбән Новгородта үзенчәлекле мөселман комплексы кору өчен акча җыю буенча Россия күләмендәге акцияләрдә актив катнаша.

Татар сәүдәгәрләре һәм промышленниклары мөселман руханиларына карата ихтирамлы мөнәсәбәттә булып, алар белән аеруча таныльган кешеләр, шул исәптән дин галимнәре белән еш очрашып торган. Ш.Мәрҗани гомеренең соңгы елларында фабрикант Алиевлар чакыруы белән Сембергә килеп, аларда кунакта була. Бу сәфәренә ул бер шәкерте белән чыга. Бөек галим һәм дин белгече үзен кунакка чакырган фабрикантлар һәм Сембернең мөселманнар җәмгыяте вәкилләре белән җирле мәчеттә намаз укый (дөрес, мәчетнең Сембердә түгел, сәүдәгәр һәм фабрикант Алиевлар утарында урнашкан булуы бар). 1880 елның июнендә И.К. Акчурин Казан сәүдәгәре Якуп Чукин йортында кунак була. Ибраһим биредәге кунаклар арасыннан таныльган татар галиме - дин белгече Ш.Мәрҗанине күреп ала. Форсаттан файдаланып, И.Акчурин галимнән: "Хәзрәт! Эшләпә кию ислам шәригате хөкеменә караганда мөселманнар өчен хәрам буламы? - дип сорый. Таныльган галим, моңа җавап йөзеннән: "Хәрам булу кайда, мәкруһ булуын дәгъва кылырга да урын юк", - ди. Әлегә сөйләшүнең асылы безгә татар дин әһеле Ризаэддин Фәхреддин аша мәгълүм.

Хәсән Акчурин да таныльган дин белгече һәм галимне яхшы белә. Аны Шиһабетдин Мәрҗани белән әле кечкенә чагында ук әтисе Т.К. Акчурин гыйбадәт кылу йортында таныштырган булса кирәк. Безнең уйлавыбызча, әлегә очрашу соңыннан малайның төрле фәннәр, беренче чиратта ислам дине тарихы, мәдәнияте һәм музей эше белән мавыгуында зур роль уйнагандыр. Бөек милләттәше белән шушы очрашып сөйләшү очрагын Х.Т. Акчурин бөтен гомере буе күңел түрендә саклый. Дөрес, алар аннан соң да очрашкалыйлар. Шундый очрашуларның берсендә Хәсән Акчурин Ш.Мәрҗанидән: "Рәсем алдырту дөресме?" - дип сорый. "Диварда асылып куелмаса, өстәл астында гына торса, зур тыю юк", - дигәнрәк җавап ишетә ул.

Хәсән Акчурин таныльган мөселман фәлсәфәчесе, дин һәм сәясәт эшлеклесе әл-Әфгани Мөхәммәд бине Сафдар Җамалетдинны да яхшы белә. Алар 1887-1889 елларда Санкт-Петербургта очрашкан булса кирәк. Безнең фикеребезчә, фабрикант, меценат һәм ислам динен яхшы белүче кеше буларак, әл-Әфгани да зур тәэсир калдыра. Аның үз фотосурәтен Х.Акчуринга бүләк итүе - моның ачык дәлиле. Ул чагында бик сирәк күренеш була бу.

Татар эшмәкәрләре кайбер дин эшлеклеләре белән туганлаша да әле. Әйтик, Курамша Акчурин үзенең кызы Мәгъберүсне таныльган мәгърифәтче һәм дин эшлеклесе, Ш.Мәрҗанинең шәкерте Борһанетдин Насретдинга; фабрикант Агишевлар кызларын Саратовның дини эшлеклеләреннән берсе Енгалычевка кияүгә бирә, улларын исә Ш.Мәрҗани нәселеннән булган кызга өйләндереп, шушы бөек татар мәгърифәтчесе белән туганлаша.

Югарыда бәян ителгәннәрдән күренгәнчә, татар сәүдәгәрләре һәм промышленниклары Идел буе һәм Урал төбәгенең мөселман мәхәлләләре тормышында мөһим роль уйный. XIX гасырның икенче яртысы - XX гасырда татар эшмәкәрләренең төбәктәге мөселман җәмгыятьләренә ярдәм кулы сузып яшәве изге традициягә әйләнә. Аллаһ ризалыгы өчен башкарыла торган бу эш берничә юнәлештә алып барыла.

Беренчедән, эшмәкәрләр мәхәлләләрне игътибар үзәгенә алып, шунда даими яшиләр һәм сәүдә-сәнәгать эшчәнлеген дә шунда алып баралар. Татар сәүдәгәрләре һәм промышленникларының күпчелеге өчен хас була бу.

Икенчедән, эшмәкәрләр үзләре туып үскән җирләрдәге җәмгыятьләрнең тормышы белән даими кызыксынып яшиләр. Сәүдәгәрләр, фабрикант һәм сәүдәгәрләр бөтен Россия империясе буйлап таралган мәхәлләләренә булышып яшәргә тырышалар. Эшмәкәрләр якташлары турында кайгыртуны изге эш итеп саныйлар. Алар авылдашларының гозерләренә беркайчан да битараф калмыйлар.

Өченчедән, татар эшмәкәрләре төбәкнең генә түгел, гомумән, илнең башка өязләрендә, шәһәрләре һәм губерналарында урнашкан җәмгыятьләр ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында уңышлы эшлиләр. Бу очракта ярдәмнең ике төрле формасы кулланыла. Беренчесе - аерым бер сәүдәгәрләр һәм фабрикантларның мәхәлләләргә ярдәм итүе, шул исәптән мәчетләр төзүе. Икенчесе - эшмәкәрләрнең төбәк һәм бөтен Россия күләмендәге төрле хәйрия акцияләрендә катнашуы.

Дүртенчедән, татар сәүдәгәрләре һәм промышленниклары дини кешеләр белән тугандашлык мөнәсәбәтләре корырга тырыша. Бу исә эшмәкәрләрнең аң-белемен, мәдәниятен арттыруга ярдәм итә.

Наил ТАИРОВ,
тарих фәннәре докторы

"Таян Аллага" конкурсына йомгак ясалды

18 декабрь көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан оештырылган III "Таян Аллага" әдәби конкурсының җиңүчесе билгеле булды. Ул - Казан (Идел буе) федераль университетындагы Филология һәм сәнгать институты студенты Алмаз Мансуров.

Исегезгә төшерәбез: әлеге конкурсны 2010 елда Вәлиулла хәзрәт Якупов башлап җибәргән иде.

Быелгы конкурста үзләренең дини эчтәлектәге әсәрләре белән 26 кеше катнашты. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге мөдире Айдар Карибуллин сүзләренә караганда, конкурсны уздыруның төп максаты булып, узган гасыр башында зыялы татар әдипләре тарафыннан нигез салынган традицияләрне торгызу тора.

Конкурсның исеменә килгәндә исә, ул халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның балаларга атап язылган "Таян Аллага" шигыреннән алынган. Билгеле булганча, Тукай - Ислам тематикасына караган бик күп әсәрләр авторы, шуңа күрә жюри нәкъ менә аның традициясен дәвам итүчеләрне сайлап алырга тырышкан.

Жюри составына быел филология фәннәре докторы, КФУ профессоры Фоат Галимуллин; Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге мөдире Фәридә Хәсәнова; "Чын мирас" журналының баш мөхәррир урынбасары Рамил Хананов; шагыйрь, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Ркаил Зәйдулла; Татарстан Милли китапханәсенең фәнни эшләр буенча директор урынбасары Ирек Һадиев кергән иде.

Башка еллардан аермалы буларак, быелгы конкурста иң яшь һәм иң өлкән катнашучылар да билгеләп үтелде. Шулай итеп, Чүпрәле районында яшәп ятучы шагыйрь Рафаэль Сиражи (аңа 74 яшь) иң өлкәне булса, Энҗе Әхмәтҗанова - иң яше дип табылды.

Конкурс берничә номинациядә узды. Жюри әгъзаларының бердәм фикере буенча, "Проза" номинациясендә иң яхшы әсәр авторы булып Дилбәр Булатова танылды. II урын Зөһрә Вилдановага бирелсә, III урын - Зөлфия Шәйхетдиновада.

"Шигърият" номинациясендә I урынны Руслан Сөләйманов яулады, II һәм III урыннарны Нурфия Халикова белән Илнар Нотфуллин бүлеште.

"Аерым жанрларны үстерү" номинацияләре буенча да жиңүчеләр билгеләп үтелде: алар - Рузилә Абдушова белән Раилә Галиева (драматургия) һәм Гөлнур Корбанова (балалар әдәбияты). Азат Йосыпов (публицистика), Фәнүс Хәбибуллин (проза), Гүзәл Сафина (шигърият) кызыксындыру бүләкләренә ия булды.

Шунысы игътибарга лаек: өченче конкурска йомгак ясалу белән үк, 2013 ел бәйгесенә старт бирелде. Әсәрләрне Татарстан мөфтияте адресына (420111 Казан шәһ., Лобачевский ур., 6 нчы йорт) җибәрергә кирәк булачак. Киләчәктә әдәби әсәрләрдән торган җыентык та басылып чыгар, дип көтелә.

Газета укучыларыбыз игътибарына III "Таян Аллага" конкурсында Гран-прига лаек булган Алмаз Мансуров иҗатыннан бер хикәя һәм шигырь (аста) тәкъдим итәбез.

Фотода: конкурс җиңүчесе Алмаз Мансуров Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге мөдире Айдар Карибуллин (сулда) һәм жюри әгъзасы, КФУ профессоры Фоат Галимуллин (уңда) белән.

Нияз САБИРҖАНОВ

Алмаз МАНСУРОВ

Гади рәсем фәлсәфәсе

Якынлашып килүче бәйрәм миндә әллә нинди татлы хисләр өермәсе кузгата. Талгын гына искән җилгә йөземне куям да, дулкынландыргыч хатирәләр дөньясына чумам.

Бу хәл нәкъ бер ел элек булды. Ватанны саклаучылар көне уңаеннан миңа бер кыз бүләккә төргәк бирде. Аның эчендә ни барын белмәсәм дә, ул миңа шундый көчле тәэсир итте ки, ничек шатлануымны күз алдына да китерә алмыйсыз. Белмим, бу минутларда минем күңел кылларыма нәрсә кагылып үткәндер, ләкин төргәкне сүткәнче үк бүләкне яратып өлгергән идем инде мин. Бәлки моңа минем эчке сиземләвем ярдәм иткәндер, ә бәлки төргәкнең бер почмагына язылган "Йөрәк дустыма" сүзләре йогынты ясагандыр.

Ә төргәктә гади бер рәсем иде. Һәм анда үзәк өзгеч сугыш күренеше тасвирланган. Өс-башы сәләмә, киеме теткәләнеп беткән, бер кулы яралы совет сугышчысы, граната тотып, фашист танкына таба үрмәли. Ә танк, үләксәләр белән тулы шыксыз кырда үзен хужа санап, үкерә-үкерә кортка охшап калган кеше өстенә килә. Солдат янындагы чокырларда, һавага күтәрелгән балчык артында үлем сагалап торган төсле тоела.

Үзем дә сизмәстән, карашымны рәсемнең өске ягына, һавага күчердем. Анда бернәрсә дә юк диярлек, бары авыр соры болытлар тасвирланган. Тукта!.. Ялгышканмын, бер кош бар икән. Әйе, әйе... Әле ул бик матур да, тик бик борчулы гына. Кош кәкрәйгән, затлы каурыйларын күперткән һәм, нәни томшыгын ачып, җиргә төбәлгән. Гүя рәсемдә аның: "Туган ягымның батыр улын харап итәләр, үтерәләр!" - дип кычкырган мәле тасвирланган.

Мин үземнең хис-тойгыларыма бирелдем һәм рәсемне үзгәртергә, аңа ниндидер якты бер нур кертергә теләдем. Бармагым белән солдат кулында коточкыч булып күренгән гранатаны капладым. Шушы кечкенә генә явызлык билгесен алып атудан рәсемдә берни дә үзгәрмәде. Шулай ук кеше өстенә танк килә.

"Граната юкка чыккач, димәк, ул аны ыргыткан... Шулай булгач, фашист танкы шартлаган булып чыга", - дип уйладым да, учым белән танкны капладым. Юкка сөенгәнмен икән. Каенлыкның исән калган башыннан тагын бер коточкыч машина чыгып килә. Мин аны да тиз генә юк иттем.

Рәсем бушап калды. Хәзер анда тынычлык. Тик барыбер нидер җитми, нәрсәдер күңелне тырный. Әйе, бу андагы җимереклек икән. Шушы кечкенә генә кәгазь битенә тасвирланган мәхшәр. Күпме гүзәллекнең башына җиткән сугыш, күпме бер гөнаһсыз кешеләр, кош-кортлар һәлак булганнар.

Рәсемне читкә алып куйдым да, уйлар диңгезенә чумдым. Дус кызымның бу иҗат җимешенә үзгәрешләр кертергә кирәкми дигән нәтиҗәгә килдем. Ни өченме? Чөнки анда тасвирланган һәр деталь чынбарлыкны ачык чагылдыра, уйлануларга этәрә һәм нәтиҗәләр ясарга ярдәм итә.

Үзенең гомерен дә жәлләмичә, патриотик хисләр кичереп, туган илен саклаучы солдат. Ләкин кирәкме икән аңа бу сугыш? Бәлки аның тынычлыкта, иле белән горурланып, аңа хезмәт итеп яшисе киләдер? Ә сугыш? Сугышны кем чыгара соң? Сугыш чыгаручыны "кеше" дип атап буламы? Күрә торып туган илен талауга, бетерүгә, ә туган халкын үлемгә дучар иткән кешене "патриот" дип атап буламы? Юк кебек...

Без XXI гасырда яшибез. Батырлык, Туган илгә мәхәббәт сугышта, я булмаса күкрәгеңне фашист пулясы астына куюда түгел, ә жиребездә тынычлык, бердәмлек һәм гүзәллек саклауда чагыла. Киләчәк буынга сәламәт җәмгыять калдыру - безнең бурычыбыз!

Рәсемгә килгәндә, мин аны әле дә саклыйм. Минем өчен аеруча "Йөрәк дустыма" сүзләре кадерле. Әйе, дус кызым йөрәгеннән чыкканнарны кәгазьгә төшерә алган, ә мин аның әйтәсе килгән фикерен тотып ала белдем. Шулай итеп, дус кызымның йөрәк дустына әверелдем.

Рәхмәт, кыш!

Тәрәзәгә гүзәл бизәк сала,
Салкын пыяланы чуарлый.
Кыш ясаган рәсем кабатланмас,
Карап торам аны тын алмый.

Ә урамда тыныч түгел бугай
Ишетелә ямьсез, әче тавыш.
Бозны эретәм дә, тышка карыйм.
Күңелемә үтеп керә сагыш.

Матурлыкка сәҗдә кылган мәлне
Урам хәлләре дә онытылган.
Ә кыш уяу, җирне пакьләр өчен
Ак кар коя салкын болытыннан.

Рәхмәт, кышка! Аз булса да каплый,
Гөнаһларны безнең күңелдәге.
Ямьсезлекне яшерә бизәк ясап,
Тәрәзәгә өйнең түрендәге.

Аллаһ үзенең яраткан колын сынауга тартыр

(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)

Әгәр мөәмингә сынау килсә, ул: "Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигүн", - дип әйтергә, яисә: "Кадәруллаһи вә мәә шәә фәгалә", - диярге тиеш. Әмма кеше тормышындагы иң кадерле һәм иң мөһим вакыт - ул авырлыклардан соң Аллаһка әйләнеп кайту, бәла-казалардан, хәсрәттән бары тик ул гына җиңеллек бирә алганын аңлау.

Аллаһы Тәгалә әйткән: "Һәрхәлдә, сезне бераз куркытып, ачлык биреп, малларыгызны киметеп, нигъмәтегезне азайтып, якыннарыгызның җанын алып сыныйбыз. Түзем булганнарга сөенеч бир, алар әйтерләр: "Без Аллаһ бәндәләре һәм Аңа әйләнеп кайтачакбыз". Алар Аллаһның рәхмәтенә һәм ярлыкавына лаектыр. Туры юлны тапканнар да шулар булыр.

Иманлы бәндә үзенә килгән бәла-казадан нәтиҗә ясый белергә тиешле. Шуның аркасында килгән зыян зурмы, ул безнең файдагамы? Әгәр дә ныклап уйлап карасак, без алганы зуррак һәм файдалырак икәнен, Аллаһның безнең язмышыбызны хәерлерәк итеп яратканын күрербез. Монысы - бер булса, икенчедән, бу бәла-казалар миңа гына түгел бит дип уйлау, һәм гомереңнең иң бәхетле минутларын күздән кичереп, Аллаһка шөкер итү шулай ук иманнандыр.

Ибн Мәсгүд әйткән: "Һәрбер шатлыклы мизгел өчен кайгылы мизгел булмый калмастыр, шатлык белән тулмаган йорт юктыр, әмма алар да кайгы белән тулмый калмастыр". Ибн Сирин әйткән: "Яшькә коенмаган көлү булмастыр". Шуны аңларга кирәк: паникага бирелү авырлыкны җиңеләйтми, ә бәлки авырайта гына. Синең паникага бирелүең дошманнарыңны гына сөендерәдер. Димәк, шайтанны сөендерәсең һәм шул ук вакытта синең кайгыга каршы тора алуың кими, шулай итеп, савабың да кимидер.

Билгеле, сынауны үткән вакытта күркәм сабырлык кирәктер, сиңа килгән бәла-казаны кемнәндер күрү, үз-үзеңне гаепләү яхшы түгелдер. Аллаһның сынавыннан куркырга вә канәгатьсезлек күрсәтергә кирәк түгелдер, бәлки аны үтү юлларын эзләргә кирәк, Аллаһы Тәгаләнең сезнең тырышлыкны буш калдырмасын уйларга кирәктер. Бигрәк тә сезне Сынаучы сезгә караганда акыллырак һәм рәхимлерәк икәнен, сынауны Ул сезне бетерү өчен түгел, ә бәлки сезнең иманыгызның ныклыгын тикшерү өчен биргәнлеген истә тотып, Аннан ярлыкау сорауны, гыйбадәт кылуны беркайчан да туктатырга кирәкмидер. Сезгә биргән бәла-каза, кайгы белән Аллаһ сезнең җаныгызны чистартканын да аңларга кирәк, шуның белән Аллаһ сездәге тәкәбберлекне, эгоизмны куадыр, бәлки бу сыйфатлар ахирәттә сезгә һәлак итүче нәрсәләрдән булыр иде.

Шуны да истә тотарга кирәк: бу дөньядагы авырлыклар ахирәт тормышын җиңеләйтә, бу дөньяда аз-маз бәла-каза күреп, ахирәттә мәңгелек бәхет-сәгадәттә булу хәерлерәктер. Безгә Пәйгамбәребезнең (сгв): "Җәннәт бик күп авырлыклар белән әйләндереп алынгандыр, ә җәһәннәм бик күп теләк һәм нәфес белән уратылгандыр. Бу тормыш имансызга җәннәт, ә иманлыга төрмәдер", - дигән хәдисен искә төшерү кирәк.

Мөселманга кайгы килсә - аның иманы сабырлыкка, шатлык килсә - шөкергә тарта. Шуның өчен Аллаһтан бүләк аласын ул онытмый. Ялгышып гөнаһ кылса, тәүбәгә ашыга һәм гөнаһыннан арына. Изгелек кылса, аны жиренә житкереп үтергә тырыша. Жыеп кына әйткәндә, мөселман үзе кылган һәрбер гамәлдән савап алып, Аллаһның рәхмәтенә омтыла.

Аллаһ Раббуль Гыйззә һәрбарчаларыбызга күркәм сабырлыклар бирсә иде. Әмин!

Жәүдәт хәзрәт ХАРРАСОВ,
Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Президиум әгъзасы,
Тукай районы имам-мөхтәсибе

Әниемнен дә намаз укуын телим...

Мин әниемнең ислам дине кануннарын төгәл үтәп баруын бик тә телим... Аның кабаттан намаз укый башлаячагына өметләнәм. Бервакыт ул намазларны үти башлаган иде, ләкин соңрак, кызганыч, ташлады. Миңа нәрсә эшләргән Киңәш биргез, зинһар! Ул Аллаһы Тәгаләнең барлыгына ышана, ләкин мин: "Әни, әйдә, намазларны да укый башла", - дигәч, төрлесен әйтә: я "вакытым юк" ди, я ниндидер сәбәпләр китерә. Әнием эшли. Әтием бу елның башында вафат булды.

Лилия, Чаллы шәһәре

Сезнең соравыгызга дини күзлектән Татарстанның Кама буе төбәге казые Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ җавап бирә:

- Пәйгамбәребез Саллә-ллаһу галәйһи үә сәләм әйткән: "Һәр гамәл ниятеңә карап бәяләнә…"

Ниятегез изге, Аллаһ кабул кылсын. Әмма белем аз булу сәбәпле, изге ниятләрне дә тормышка ашырганда кеше хаталанырга мөмкин. Шуңа күрә "Мин мөселман" дип кенә Исламның биш баганасын тану һәм үтәү аз. Әлбәттә, намаз адәм баласына фарыз итеп йөкләтелгән мәҗбүри гамәл һәм бу хакта Аллаһы Тәгалә Корәни-Кәримдә әйтә: "Дөреслектә, намаз, вакыты билгеләнгән фарыз гамәл итеп, мөэминнәргә йөкләтелде" ("Ән-Ниса (Хатыннар)" сүрәсенең 103 нче аяте; Ногмани тәфсиреннән).

Кешене мәҗбүриләргә кирәк түгел. Намазның әһәмиятен, намазын укымаган кешеләргә ирешә торган җәзаларны йомшаклык белән аңлатырга кирәк. Бу, беренче чиратта, ата-ана белән булган мөнәсәбәткә кагыла һәм бу хакта түбәндә китереләчәк вакыйгада бик яхшы күренә.

Бер кеше Сәгыйд бине әл-Мөсәйб янына килә һәм: "Мин ата-анага мәрхәмәтлелек турындагы Коръән аятенең "Аларга күркәм сүзләр әйт" дигән өлешеннән башка бөтенесен дә аңладым, миңа шушы сүзләрнең мәгънәсен аңлат", - дигәч, ул: "Кол үзенең хуҗасы белән нинди мөнәсәбәттә булса, син дә ата-анаң белән шундый мөнәсәбәттә булырга тиешсең", - дигән.

Аллаһы Тәгаләдән әниеңнең намазга басуын сорап дога кылырга кирәк.

Догаларны кабул кылучы - бары тик Аллаһы Тәгәлә генә. Иншалла, әгәр дә әниеңә карата күркәм холыклы булып, һәрвакытта яхшы мөнәсәбәттә булсаң, догаларыңны Аллаһы Тәгалә кабул итәр һәм әниең намазга басар.

Күңел күзең сукыр булмасын

Сау-сәламәт, өрлек кебек ир-егетләрнең кризиска, заманага сылтап, түбән тәгәрәүләрен күреп, йөрәк әрни. Ә бит арабызда бик ачы язмышлы, батыр йөрәкле кешеләр бар, шаклар катарлык. Шундый ирләрнең берсе Мамадыш районының Түбән Тәкәнеш авылында яши. Рафаил абый Фәләхов ул. Аның дөм сукыр калуына инде ун ел икән.

Кечкенәдән табигатькә гашыйк Рафаил абый, бераз үскәч, табигать күренешләрен кәгазьгә төшерә башлый. Кызыклы, матур күренешләрне фотога төшерү белән дә мавыга. Баш-аягы белән иҗатка чумган, ислам динен куәтләп шигырьләр, нәсерләр язу белән дә мавыккан Рафаил абыйның әсәрләре газеталарда басыла. Ә төп һөнәре иҗаттан ерак була аның - рентгенолог-лаборант. Аннан - электрик. "Ул вакытта трансформаторлар бик иске иде, кыска ялганыш нәтиҗәсендә шартлау булды һәм очкын-ялкын күземә бәрде, - дип сөйли Рафаил абый. - Күп тә үтмәде, башта бер күзем сукырайды, өч ел узгач, икенчесе дә күрми башлады. Бу - сәламәтлек өчен зарарлы һөнәрләрем нәтиҗәседер инде. Дөм сукырлыкта яшәү баштарак бик авыр булды. Нишләргә белмичә, ишегалдында көннәр буе бәрелә-сугыла йөри идем. Эч пошуга түзәр чамам калмый иде. Гомер юлында нинди генә кыенлыклар кичерсәм дә, бу кадәр чарасызлыкта калганым юк иде. Хатыным Илсөягә рәхмәт, ул нык сабырлык күрсәтте, ярдәм итте". Рафаил абый белән инде 41 ел янәшә атлаучы Илсөя апа, чыннан да, ирен көйләп кенә тора. Бергәләп алты бала үстергәннәр: дүрт кыз, ике малай. Ләкин Фәләховлар гаиләсенә бала хәсрәте дә кичерергә язган икән: "Казаньоргсинтез" заводында эшләүче кызлары фаҗигале төстә үлеп киткән. Аның сабый баласын Рафаил абый белән Илсөя апа тәрбияләп үстергән.

- Мин кайвакыт көненә ике-өч шигырь язам, тик аларны күчерергә Илсөянең генә вакыты аз, аның эше бик күп, - ди Рафаил абый. - Төнге уникедә дә торып язам, таң атканда да. Язылган өстенә язылмасын дип, бер юл язам да, кәгазьне бөклим, аннан тагын язам, тагын бөклим. Бер фикеремне язып куйыйм әле дип утырам да, китә инде шуннан... Хәзерге вакытта алты китап чыгарырлык материалым бар. Бер өлешен басмага әзерлиләр дә инде, ярдәм итүчеләр табылыр дип ышанам.

Рафаил абый белән Илсөя апаның биш баласы да авыл тормышын сайлаган. Унике оныклары бар. Гөрләтеп яшәп яталар.

- Балалар бик булыша, алар булмаса мал да асрый алмас идек. Аллага шөкер, бик игелекле, шәфкатьле, тәртипле булып үстеләр. Әле менә өйгә су керттеләр, - дип сөенеп сөйли Илсөя апа.

Җиңел гәүдәле, ачык йөзле, тәмле телле, сөйкемле бу апага 65 яшьне һич тә бирерлек түгел. Тәкәнеш урта мәктәбендә 37 ел башлангыч сыйныфларны укыткан ул.

Якты дөньяны күрмәгән килеш тә аның матурлыгын тоеп, шигырьләр язучы Рафаил абыйга, сабыр, итагатьле Илсөя апага карап сокланып утырдым. Менә нинди парлардан үрнәк алып яшәргә кирәк! Тормышның гүзәллеген күрү өчен маңгай күзенең генә ачык булуы җитми шул, ә күңел күзенең ачык, якты булуы кирәк.

Фирая МИҢНЕГАЛИЕВА,
Мамадыш

Казанда намаз вакытлары

Көн исеме	Дата	Иртәнге намаз	Кояш чыгу	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
Шимбә	22.12.12	7:43	9:13	13:02	15:09	16:12	17:42
Якшәмбе	23.12.12	7:43	9:13	13:02	15:09	16:13	17:43
Дүшәмбе	24.12.12	7:43	9:13	13:02	15:09	16:13	17:43
Сишәмбе	25.12.12	7:44	9:14	13:02	15:10	16:14	17:44
Чәршәмбе	26.12.12	7:44	9:14	13:02	15:11	16:15	17:45
Пәнҗешәмбе	27.12.12	7:44	9:14	13:02	15:11	16:16	17:46
Җомга	28.12.12	7:44	9:14	13:02	15:12	16:17	17:47
Шимбә	29.12.12	7:44	9:14	13:02	15:13	16:18	17:48

Руслан САБИРОВ:

МИҢА НӘСЕЛНЕ АГАРТУЧЫ, НИГЕЗНЕ САКЛАП ТОРУЧЫ, ДИЛӘР

Тарихи-мәдәни мирас елы кысаларында игълан ителгән Коръән елы уңаеннан, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Коръәни-Кәримгә булган игътибарны һәм ихтирамны арттыру өлкәсендә шактый нәтиҗәле эшләр башкарды. Шулар арасында күптән түгел Россия ислам университетында уздырылган Коръән укучылар конкурсы аеруча зур игътибарга лаек. Республикабыздагы иң яхшы Коръән укучыларны берләштергән бәйгенең җиңүчесе булган 23 яшьлек Руслан Сабировка шул уңайдан берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

- Дингә килүең ничегрәк булды? Коръән укырга кайчан өйрәндең?

- 15 яшьләрдә Буа мәдрәсәсендәге махсус курсларга йөри башлаган идем, шуннан кызыксынып киттем. "Мөгаллим сәни" аша хәрефләрне аерырга, сүзләрне укырга өйрәндем. Кыскасы, оеткысы мәдрәсәдә салынды, калганнарын үзлегемнән өйрәндем.

- Мондый бәйгеләрдә элегрәк катнашканың бар идеме?

- Моңа кадәр бернинди дә бәйгеләрдә катнашканым булмады. Коръән укучылар конкурсында катнашуым да кызык кына килеп чыкты. Районыбыз имам-мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Хәйбуллов: "Барып кара, катнаш, Коръән укучылар белән таныш", - дип җибәргән иде. Катнашып кына түгел, бүләкле дә булып кайттым.

- Хәрби хезмәттә булдыңмы?

- Әйе, булдым. 2009-2010 елларда Екатеринбургта хезмәт итеп кайттым. Аңа кадәр шунысын да әйтеп узасым килә: 2008 елда "Мөхәммәдия"гә кергән идем. Шул чакта: "Хәрби хезмәттән качу өчен кердең", дип әйтүчеләр дә булды. Нәтиҗәдә, бер ел укыганнан соң, әлеге сүзләрнең дөрес түгеллеген дәлилләргә теләп, армиягә киттем.

- Хәзерге вакытта дин гыйлеме алуыңны кайда дәвам иттерәсең?

- Дөрес, үзлектән генә өйрәнү җитми, остазлар да кирәк. Бүгенге көндә Буа мәдрәсәсендә белем алам. Россия ислам университетына керү теләгем дә көчле. Ноябрь аенда районыбызның Карлы авылы мәчетенә имам-хатыйб итеп билгеләделәр. Әлеге вазифа зур җаваплылык сорый, шуңа да кайбер хыялтеләкләрне чикләргә туры килә.

- Гаиләгез дониме?

- Гаиләдә мин генә динне тулысынча тотам. Әти-әниләр сөенәләр генә, бернинди дә каршылык юк. Минем турыда "нәселне агартучы, нигезне саклап торучы", диләр.

Әңгәмәдәш -
Алинә БИКМУЛЛИНА

Кабан арты мәчетенең социаль ашханәсе ремонтка ябылды

Кабан арты мәчете - Ислам динен кабул итүгә мең ел исемендәге мәдрәсә узган гасырның 90 нчы елларыннан бирле мохтаҗларга ярдәм итеп килә.

Мохтаҗларны җылы ризык белән тәэмин итү максатыннан, 2008 елда мәчет каршында социаль ашханә ачылган иде. Төрле кыен хәлдә калучылар өчен әлеге ашханә бердәнбер туклану урыны булып торды. Монда даими рәвештә күп балалы гаиләләр, студентлар, караучысыз калган өлкәннәр, инвалидлар, авыр хәлдәге кешеләр тукланды. Ятим балалар өчен бәйрәм табыннары әзерләнде, Рамазан аенда атна саен сабыйларны мәчеткә алып килеп ифтар ашлары уздырылды. Физик яктан мөмкинлекләре чикләнгәннәргә ашамлыклар өләшенде.

Күптән түгел Кабан арты мәчетенең социаль ашханәсе ремонтка ябылды. Эшчәнлекне дәвам итү өчен ярты гасырлык бинага тиз арада капиталь ремонт ясарга кирәк. Шушы изге эштә ярдәм күрсәтүегезне сорап, иганә өчен исәп-хисап счётын бастырабыз:

Получатель: Закабанная мечеть-медресе им. 1000-летия принятия Ислама

Расчетный счет № 40703810000020004299, кор. счёт № 30101810000000000805, ИНН 1655031361, БИК 049205805, КПП 165501001 в "АК БАРС" банке г. Казани. Назначение платежа: Благотворительность. На ремонт Социальной столовой. Электронные кошельки: Яндекс-кошелек: 410011607772122. Web money: R443094877139. Татарстан, г. Казань, ул. Х.Такташа, д. 26, тел.: 278-00-30, 537-12-83.

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 25 (168) чыгарылыш.
Гамәлгә куючы һәм нәшир: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
Баш мөхәррир: Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
Мөхәррир: Нияз САБИРҖАНОВ.
Дизайнер: Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
Тираж: 5000 данә. **Заказ:** 9430.
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.
Редакция адресы: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
График буенча бу санга 20 декабрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.
Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.
Электрон адрес: niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!